**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы**
**Иске Маҗын авыл җирлеге составына кергән Иске Маҗын торак пунктында**
**халык җыены нәтиҗәләре турында**

**14.11.2020ел.** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 14 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде: "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Маҗын авыл җирлегенең Иске Маҗын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

- авыллар эчендәге юлларны ремонтлау: Иске Маҗын торак пунктында М.Җәлил урамында юлларны планлаштыру, торгызу, асфальт валчыгы тарату;
- ТР Минзәлә муниципаль районы Иске Маҗын торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү: үсемлек грунтын алу, комлы нигез ясау, вак таштан тротуар ясау, эскәмияләр урнаштыру, инеш аша күперчек урнаштыру, чишмә алдында металл чыбыклардан мәйданчык ясау (эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- ТР Минзәлә муниципаль районы Иске Маҗын торак пунктында, Холодный Ключ торак пунктында, Гришкино торак пунктында җәйге чорда территорияләрнең үләнен чабу (эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 240 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 126 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 126 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Маҗын авыл җирлегенең Холодный Ключ торак пунктында халык җыены узуын танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

"2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Маҗын авыл җирлегенең Холодный Ключ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, БВС һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары,күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган граждannадан тыш) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны танырга һәм түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- авыллар эчендәге юлларны ремонтлау: Иске Маҗын торак пунктында М.Җәлил урамында юлларны планлаштыру, торгызу, асфальт валчыгы тарату;
- ТР Минзәлә муниципаль районы Иске Маҗын торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү: үсемлек грунтын алу, комлы нигез ясау, вак таштан тротуар ясау, эскәмияләр

урнаштыру, инеш аша күперчек урнаштыру, чишмә алдында металл чыбыклардан мәйданчык ясау (эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

- ТР Минзәлә муниципаль районы Иске Мажын торак пунктында, Холодный Ключ торак пунктында, Гришкино торак пунктында җәйге чорда территорияләрнең үләнен чабу (эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3. Иске Мажын авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Мажын авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Җыенда рәислек итүче,**
**Минзәлә муниципаль районы** ____________ **Э.Р. Шәймәрданов**
**Иске Мажын авыл җирлеге башлыгы**